КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 4 май г.Казань № 361

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 ноябрь, 1050 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан

субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 ноябрь, 1050 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Кытай Халык Республикасыннан» сүзләрен «чит ил дәүләтләреннән» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «Кытай Халык Республикасыннан» сүзләрен «чит ил дәүләтләреннән» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

исемендә «Кытай Халык Республикасыннан» сүзләрен «чит ил дәүләтләреннән» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «Кытай Халык Республикасыннан» сүзләрен «чит ил дәүләтләреннән» сүзләренә алыштырырга;

2 нче пунктта «Кытай Халык Республикасыннан» сүзләрен «чит ил дәүләтләреннән» сүзләренә алыштырырга;

3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Субсидия бирү шарты – конкурс нигезендә сайлап алуда җиңү. Конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү конкурс комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе составы, конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү вакытлары, конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга заявкалар кабул итү вакытлары Вәкаләтле орган тарафыннан раслана.

Вәкаләтле орган үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында конкурс нигезендә сайлап алу, конкурс нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр турындагы, конкурс нигезендә сайлап алу вакытлары турындагы мәгълүматны – конкурс нигезендә сайлап алу башланган көнгә кадәр җиде календарь көннән дә соңга калмыйча, конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары турындагы мәгълүматны конкурс нигезендә сайлап алу тәмамланган көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгаруны тәэмин итә;

4 нче һәм 5 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидия алу хокукына түбәндәге критерийларга туры килә торган коммерциягә карамаган оешмалар ия:

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән юридик зат булу;

татар телен, фәнне, мәгарифне, милли мәдәниятне, тарихи мирасны, халык педагогикасын, демографиясен үстерү өлкәсендә программаларны тормышка ашыруда тәҗрибәсе булу;

Россия Федерациясе субъектларында һәм аннан читтә кимендә рәттән өч ел яшәүче ватандашларга ярдәм күрсәтү чараларын үткәрү;

соңгы уку елында дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча чит ил дәүләтләреннән белем алган татар диаспорасы вәкилләре саны булу.

Конкурс нигезендә сайлап алу критерийларын бәяләү мәгънәләре Министрлык боерыгы белән билгеләнә.

Субсидия алучы субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килгән айның беренче көненә карата түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

субсидия алучы бетерү, үзгәртеп оештыру процессында булмаска тиеш, аңа карата банкротлык процедурасы башланмаган, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган булырга тиеш;

субсидия алучы чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булмаска тиеш;

субсидия алучы бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш;

субсидия алучының Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмаска тиеш;

субсидия алучының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаска тиеш.

5. Субсидия алучы түбәндәге документларны Вәкаләтле органга кертә:

субсидия бирү турында гариза;

субсидия алучының гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турындагы документлар күчермәләрен;

субсидия алучының җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләрен;

субсидия алучының җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм субсидия алучының бетерү, үзгәртеп оештыру процессында булмавы, аңа карата банкротлык процедурасы башланмавы, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавы турында булган гарантия хатын;

субсидия алучының җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланмау, шулай ук субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмавы турында булган гарантия хатын;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган документны;

штат расписаниесен;

гариза бирү көненә кадәр килгән соңгы ике ел өчен субсидия алучының татар телен, фәнне, мәгарифне, милли мәдәниятне, тарихи мирасны, халык педагогикасын, демографиясен үстерү өлкәсендә программаларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеге турында мәгълүмат;

субсидия алучы тарафыннан Россия Федерациясе субъектларында һәм аннан читтә кимендә рәттән өч ел яшәүче ватандашларга ярдәм күрсәтү буенча үткәрелгән чаралар турында мәгълүмат;

раслый торган документларны теркәп, соңгы уку елында дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча чит ил дәүләтләреннән белем алган татар диаспорасы вәкилләре турында мәгълүматлар;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгымнарның субсидия алучы җитәкчесе тарафыннан расланган сметасын;

Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан аңа карата субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешенә тикшерүләр үткәрүгә ризалыгын.

Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бу пунктның җиденче абзацы белән күздә тотылган документ тапшырылмаган очракта, Вәкаләтле орган әлеге документны дәүләт хакимиятенең тиешле органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Тапшырылган документларның күчермәләре субсидия алучының җитәкчесе тарафыннан раслана.»;

6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Гаризаларны карап тикшерү конкурс комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән җиде эш көне эчендә бу Тәртипнең 5 нче пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә.

Конкурс комиссиясе составы Вәкаләтле орган тарафыннан раслана һәм кимендә 5 кеше тәшкил итәргә тиеш. Конкурс комиссиясе составына

квалификацияле белгечләр, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре, галимнәр һәм мәгариф һәм фән өлкәсендә казанышлары булган башка затлар кертелергә мөмкин.

Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре саны конкурс комиссиясе составының 1/3еннән артмаска тиеш.

Конкурс комиссиясе карары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә. Карар кабул иткәндә конкурс комиссиясенең катнашучы әгъзаларының минималь саны – 4 кеше. Тавышлар саны тигез булганда, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы, ә ул булмаганда – конкурс комиссиясе рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч була.

Конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү процедурасын бозулар булганда, конкурс нигезендә сайлап алуда катнашучы конкурс комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция конкурс комиссиясе рәисе исеменә, конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре игълан ителгәннән соң, календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн ирекле рәвештә язып бирелә.

Конкурс комиссиясе апелляция бирү вакыты тәмамланган көннән бер эш көне эчендә апелляцияне карап тикшерә. Апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карарлар конкурс комиссиясе тарафыннан, ачык тавыш биреп, конкурс комиссиясе утырышында катнашучылар санынннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булган очракта, конкурс комиссиясе рәисе хәлиткеч тавыш хокукына ия. Апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен чыгара: апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклау турында; апелляцияне канәгатьләндерү турында.

Карар утырышта катнашучы конкурс комиссиясе рәисе һәм барлык әгъзалары кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Конкурс нигезендә сайлап алуда катнашудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

конкурс нигезендә сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 4 нче пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

документлар пакетын документларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән соңрак тапшыру.

Конкурс нигезендә сайлап алуда катнашудан баш тарткан очракта, Вәкаләтле орган, гаризаларны кабул итү вакыты тәмамланган көннән җиде эш көне үткәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә конкурс нигезендә сайлап алуда катнашучыга бу турыда хәбәрнамә җибәрә.»;

7 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Конкурс комиссиясе карар кабул ителгән көннән өч көн эчендә Вәкаләтле органга конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен җибәрә. Вәкаләтле орган конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен алган көннән өч көн эчендә субсидия бирү турында йә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

конкурс нигезендә сайлап алуда катнашучының конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр исемлегендә булмавы;

субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның бу Тәртипнең 5 нче пункты белән күздә тотылган таләпләргә туры килмәве;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 5 нче пункты белән күздә тотылган документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

бирелгән документларда дөрес булмаган мәгълүматлар булу;

бу Тәртипнең 2 нче пункты нигезендә финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре туры килмәү.

Субсидия бирүдән баш тартылган очракта, кабул ителгән карар нәтиҗәләре турындагы хәбәрнамәдә баш тарту нигезләре күрсәтелә.»;

9 нче пунктта:

бишенче абзацта «Кытай Халык Республикасыннан» сүзләрен «чит ил дәүләтләреннән» сүзләренә алыштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләре;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән өстәмә хисаплылык бирү вакыты, формасы һәм тәртибе;»;

түбәндәге эчтәлекле унөченче абзац өстәргә:

«Кирәк булуга карап, Вәкаләтле орган субсидия алучы белән килешүгә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән билгеләнгән бертип форма нигезендә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

10 нчы пунктның беренче һәм дүртенче абзацларында «Кытай Халык Республикасыннан» сүзләрен «чит ил дәүләтләреннән» сүзләренә алыштырырга;

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Субсидия бирү нәтиҗәсе – дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча чит ил дәүләтләрдән белем алган татар диаспорасы вәкилләре саны кимендә 20 кеше булу.»;

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Субсидия алучы хисап елының 1 декабренә кадәр Вәкаләтле органга бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап кертә.»;

14 нче пунктта:

өченче абзацта «субсидиядән файдалану турындагы» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы» сүзләренә алыштырырга;

алтынчы абзацта «нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәсенә» сүзләренә алыштырырга;

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.»;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче мәгариф программалары – бакалавриат программалары, белгечлек программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча чит ил дәүләтләреннән татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 4 май, 361 нче карары редакциясендә)

Форма

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап

| Т/с | Чит ил дәүләтләреннән белем алган татар диаспорасы вәкилләре саны, кеше | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Җитәкче _______________ _____________ ________________________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

20__ ел, «__» ________

____________________________________